Совет
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
Староматакского сельского
поселения Алькеевского
муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Әлки муниципаль районы
Иске Матак авыл жирлеге
Советы

Адрес: 422890, РТ, с. Старые Матаки, ул. Центральная , 4
тел: : 8 (84346) 79-2-12

Адресы: 422890, РТ, Иске Матак авылы, Үзәк ур.,4
факс: 8 (84346) 79-2-12

**РЕШЕНИЕ** Иске Матак авыл **КАРАР**

2022 елның 9 марты 38 №

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы «Иске Матак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон (соңгы үзгәрешләр белән), 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Әлки районы прокуратурасының хокукый инициативасын өйрәнеп, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы «Иске Матак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 85,86 статьясы нигезендә Иске Матак авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы "Иске Матак авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Советының 2018 елның 11 октябрендәге 27 номерлы карары ( 2019.11.12, 22№, 2020.23.10,8№ үзгәрешләр белән) белән расланган Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә (1нче кушымта).

2. Әлеге карар гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә.

3. «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы «Иске Матак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.

4. «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы «Иске Матак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карарны, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы «Иске Матак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының яңа редакциясен дәүләт теркәвенә алганнан соң Иске Матак авыл җирлеге территориясендә Татарстан Республикасы, Әлки районы, Иске Матак авыл , Үзәк ур., 4 йорт (җирле үзидарә бинасы), Иске Матак авыл, Үзәк урамы, 7а йорт (авыл мәдәният йорты) адресы буенча махсус җиһазландырылган стендларда урнаштырырга һәм Әлки муниципаль районының рәсми http://alkeevskiy.tatarstan.ru. сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми pravo.tatarstan.ru порталында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Әлки муниципаль районы Иске Матак авыл җирлеге башлыгы урынбасарына йөкләргә.

Әлки муниципаль районы
Иске Матак авыл җирлеге Советы Рәисе: М.М.Худякова